Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.03.2023 ел Менделеевск ш. №176

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 28 февралендәге 115 номерлы,
2021 елның 27 сентябрендәге 657 номерлы
карарларына үзгәрешләр кертү турында

Менделеевск шәһәре территориясендә урнашкан биналарны һәм корылмаларны тотуга, ремонтлауга һәм реставрацияләүгә бердәм таләпләр тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре советының 2019 елның 5 июнендәге 78 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 28 февралендәге 115 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан биналарның һәм корылмаларның фасадларын карап тотуга, ремонтлауга һәм реставрацияләүгә таләпләр турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан биналарның һәм корылмаларның фасадларын карап тотуга, ремонтлауга һәм реставрацияләүгә таләпләрнең 8 бүлегенә 8.7 пунктын түбәндәге редакциядә өстәргә:
«8.7 Бина (корылма) фасадында реклама характерындагы мәгълүматлар булган элмә тактаны урнаштыруга рөхсәт бина фасадының билгеләнгән тәртиптә килешкән колер паспорты нигезендә бирелә".

2. «Мәгълүмати элмә такталар урнаштыру, элмә такталар урнаштыру дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 сентябрендәге 657 номерлы карары белән расланган элмә такталар урнаштыру, элмә такталар урнаштыру дизайн-проекты белән килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә, үзгәрешне түбәндәге редакциядә 2 бүлекнең 2 пунктына 5 пунктчаны өстәп җибәрергә:
- «5) бина фасадының билгеләнгән тәртиптә килештерелгән колер паспорты булмау.».
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга» http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бүлегендә урнаштырырга: http://mendeleevsk.tatarstan.ru
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары А.Ф.Искаковка йөкләргә

Җитәкче Р.Р.Искәндәров